КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1053

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 974 нче; 2016 ел, 14 гыйнвар, 12 нче; 2016 ел, 2 ноябрь, 807 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1094 нче; 2017 ел, 27 июнь, 441 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 26 апрель, 296 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16.1 нче пунктның 1 графасына «спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик культура-спорт оешмалары» сүзләрен өстәргә;

16.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «30028100000000000003103 | эш | спорт резервын әзерләүне оештыру һәм үткәрү | - | - | - | - | физик культура һәм спорт | ХЭТТИ-дән сайлау». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 5 сентябрь, 638 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 15 апрель, 228 нче; 2016 ел, 29 декабрь, 1029 нчы; 2017 ел, 25 март, 180 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның 1 графасына «спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик культура-спорт оешмалары» сүзләрен өстәргә;

4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «30028100000000000003103 | эш | спорт резервын әзерләүне оештыру һәм үткәрү | - | - | - | - | физик культура һәм спорт | ХЭТТИ-дән сайлау». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин